СОВЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Ул. Красавина, д.40, с. Набережные Моркваши, 422594

Красавин ур., 40 нче йорт, Яр Буе Моркваша авылы, 422594

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ — КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

23.11.2024 с. Набережные Моркваши № 5

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Моркваша авыл җирлегенең Покровка торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Моркваша авыл җирлегенең Покровка торак пункты территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 800 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы?- Покровка торак пунктының Фурцевская урамында яшәүчеләрне су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, дигән мәсьәлә буенча 2024 елның 23 ноябрендә булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 44 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 23 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенының 23 катнашучысы тавыш бирде; «ЮК» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1 Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Моркваша авыл җирлегенең Покровка торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2 «Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Моркваша авыл җирлегенең Покровка торак пункты территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 800 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә сез ризамы? - Покровка торак пунктының Фурцевская урамында яшәүчеләрне су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү

чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, дигән мәсьәлә буенча карарны таныйрга.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3 Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Покровка торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнар җыены нәтиҗәләрен Яр буе Морквашы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4 Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: И. Х. Гаязов